Республика Татарстан
**ГЛАВА**
Пестречинского
муниципального района –
председатель Совета
Пестречинского
муниципального района
422770, с.Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы

**БАШЛЫГЫ –**

Питрәч муниципаль район
Советы рәисе
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» ноябрь, 2020 ел № 88-п

«2021 һәм 2023 еллар план чорына Питрәч муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставының 20 статьясы нигезендә, Питрәч муниципаль районы халкының Питрәч муниципаль районы бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 30 гыйнварындагы 224 номерлы карары (2017 елның 7 декабрендәге 120 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 211 номерлы, 2019 елның 24 октябрендәге 225 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Питрәч муниципаль районы территориясендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Питрәч муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга (алга таба - Совет карары проекты).

2. Билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты;

2.2. гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты - 2020 елның 1 декабре, 15.00 сәгать;

2.3. гавами тыңлаулар үткәрү урыны - Питрәч ав., Совет ур., 18 йорт, Питрәч муниципаль районы Советының зур залы;

2.4. Совет карары проекты буенча, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язылырга мөмкин булган адрес - Питрәч ав., Совет ур., 18 й., 4 нче кабинет.

3. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына:

әлеге карар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Советның карар проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.2. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар киңәшләрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, шулай ук Советның эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә;

3.3.2020 елның 4 декабренә кадәр Советның карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Интернет челтәрендә Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. «Вперед» («Алга») газетасында халык алдында тыңлаулар үткәрү турында 2020 елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча хәбәр урнаштырырга.

5. Советның карар проектын Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов